СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫҚНЫ, СӨЙ ХАЛЫҚНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

ДУСЛЫҚ

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО - ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №138 (7311) | 19 ноябрь, 1991 ел. ШИМБӘ | Бәясе 4 тиен.

Алар беренче

Норлат-Октябрь сөт-май комбинатының өлкән мастеры Асия Далгатовна КАМАЛЕТДИНОВА һәм техник контроль бүлеге начальнигы Надежда Викторовна КУДРЯШОВА майның сыйфатын билгеләү буенча республика смотр-конкурсында катнашып беренчелекне яуладылар. Җиңүчеләргә Почет грамоталары, ә өлкән мастерга акчалата премия дә тапшырылды.

Еллык план үтәлде

«Агропромэнерго» берләшмәсе. Коллектив 1 ноябрьгә еллык продукция реализацияләү күләмен 102,3 процентка үтәде. Берләшмә авыл эшчәннәренә техник хезмәт күрсәтә, электр җиһазларын ремонтлый, монтажлау эшләрен башкара һәм җибәрү-төзәтү һәм контроль-үлчәү эшләренә капиталь хезмәт күрсәтә. Коллективның куанычлы күрсәткечләрендә Михаил Сергеевич Малыгин, Александр Иванович Киселев, Рамил Хәнәфиевич Мингалимов җитәкчелегендәге комплекслы махсуслаштырылган бригадаларның хезмәт өлеше аеруча зур.

Берләшмә эшчеләре авыл эшчәннәренә хезмәт күрсәтүне дәвам итәләр. Хәзер «Заветы Ильича», Ульянов исемендәге колхозларда шактый зур күләмле эшне тәмамлап киләләр алар.

Ф. САТДАРОВ,
экономист.

Кемнең кайда һәм ничек хезмәт куюы, әлбәттә, аның тырышлыгына бәйле. Үз эшен эленке-салынкы башкара икән, димәк, бу һөнәр күңеленә ятмый. Владимир Викторович озак сайланып йөрмәде, авылда аның шуннан кала профессиясе дә юк, тотты да хуҗалыкның машина-трактор паркына механизатор булып эшкә урнашты. Аңар комбайн бирделәр, Һәм ул шул көннән бирле КСК-100 комбайны белән АВМ, сенаж өчен берьеллык үлән чапты. Көзен дә җәй үтте дип кул кушырып утырмады, Т-70 тракторы белән татлы тамыр чистартуда катнашты. Кышын Красников җәйге һәм көзге айларда кырда эшләгән авыл хуҗалыгы машиналарын ремонтлауда булды.

Тик соңгы вакытларда сәламәтлеге какшау сәбәпле генә Владимир Викторович Красников котельняга күчеп эшләргә мәҗбүр.

Рәсемдә: Синдряков исемендәге колхоз эшчесе В. В. Красников.

Хәерле сәгатьтә!

«Игенче» колхозының культура йортында үткәрелгән бу кичә аларның күңелләрендә озак сакланыр әле. Бу көнне авыл хезмәтчәннәре бирегә армиягә китәсе егетләр — Рәмис Ситдыйков, Рәфис Фәхриев, Айзат Хәсәншин һәм Рамил Абдуллинны озатырга җыйналдылар.

Беренче башлап сүзне колхоз рәисе Рифкать Әхмәдуллович Насыйбуллин алды. Ул яшьләрнең исән-сау хезмәт итеп туган колхозларына әйләнеп кайтуларын теләде һәм аларга истәлекле бүләкләр тапшырды.

Аннан соң сүз авыл Советы рәисе Рифкать Бәдретдинович Фәхриевка бирелде. Ул да яшьләрне ил чигендә уяу торырга һәм үзалларында торган изге бурычларын намус белән үтәргә чакырды.

Авыл яшьләре исеменнән булачак солдатларны шулай ук сыер савучы кыз Рәзинә Сәлахова һәм механизатор егет Илгиз Әһлиуллин, Әфганстанда хезмәт итеп кайткан Илгиз Вәлиәхмәтов та котладылар. Аларга хәерле юл, илгә-көнгә тынычлык, намуслы хезмәт итеп кайтуларын теләделәр.

Солдат егетләр бу җылы сүзләрне йөрәкләренә якын кабул иттеләр, намуслы хезмәт итәчәкләренә һәм физик авырлыклар алдында каушап калмаячакларына ышандырдылар.

Кичә бергәләп күңел ачу белән тәмамланды.

Х. ШӘФИГУЛЛИНА,
Фома авылының китапханә мөдире.

Кайда—ничек, ә бездә—бәйрәм!

Узган шимбәдә шикәрчеләр поселогы клубында бәйрәм рухы хакимлек итте. Бу көнгә завод эшчеләренә махсус әзерләнгән күчтәнәч пакетлар да бәйрәмчә кәефне көчәйтеп җибәргәндер, мөгаен.

Завод директоры Ш.В. Кашаповның чыгышы да йөрәккә үтәрдәй җан җылысы белән тулы булды. Ул бүгенге көн, киләчәккә планнар турында сөйләде, эшчеләрнең тормыш хәлен яхшырту, аларның һәр яктан материаль тәэмин ителешен кайгырту турында сүз алып барды.

Бу көнне производство алдынгыларын хөрмәтләделәр. Җиңүчеләрнең исемнәре Почет китабына, Почет тактасына кертелде. Аларга кыймәтле бүләкләр тапшырылды. Яшь әфганлы егет Наил Мусин да игътибардан читтә калмады. Чирек гасыр гомерләрен заводта эшләп уздырган ветеранларга да аерым тукталмый мөмкин түгел. Болар —КИП слесаре Владимир Петрович Зорин, известь яндыручы Валентина Ивановна Царева, ЖКО эшчесе Галина Ивановна Калашник, РУМ машинисты Ләйлә Шәфигулловна Газизовалар. Аларның предприятиедәге хезмәтләре Почет грамоталары һәм акчалата премияләр белән билгеләп үтелде.

Бәйрәм ял кичәсе белән тәмамланды: монда җыр-бию, музыка авазлары озак яңгырады.

Л. ТАФЕЕВА.

х х х

Бу көнне ит комбинаты хезмәтчәннәре бәйрәмчә бизәлгән өстәл артына җыелдылар.

Администрация үз эшчеләрен, хезмәткәрләрен үзенчәлекле бәйрәм сюрпризы белән сөендерде. Моның өчен аерым фабрика җитәкчеләре белән турыдан-туры элемтәгә чыгарга туры килде. Аның каравы бу көнне ит комбинаты хезмәтчәннәренең өстәлләрендә кондитер әйберләре пәйда булды. Бәйрәм хөрмәтенә үзебезнең продукцияне дә: ит, колбаса алдылар. Моннан тыш карабодай ярмасы, сыра һәм башка дефицит әйберләр бирелде. Бәйрәмгә акча бүләк итү дә кәефне күтәрде. Уен-көлке, җыр, бию кичкә кадәр дәвам итте. Кыскасы,искә алыр нәрсәләр бар иде бу бәйрәмдә.

Р. ЧАХМАХЧЕВ.

х х х

«Ленинский путь» колхозында да бу көн зур бәйрәм итеп билгеләнде. Биредә механизаторлар, терлекчеләр котлау алды. Ветераннарны да оныт маганнар иде, армиядән хезмәт срогын тәмамлап кайтучылар да хөрмәтләнде.

Һәркемгә җылы сүз белән бергә бүләкләр дә тапшырылды. Ветераннарга—матур итеп бизәлгән котлау кәгазе белән бергә акчалата бүләк бирелде.Ә солдаттан кайтучыларга 500 сум күләмендә материаль ярдәм, ике центнер ашлык (түләүсез) җылы курткалар бүләк ителде.

Укучылар һәм авыл яшьләре хәзерләгән бәйрәм концерты һәркем күңеленә хуш килде, әйбер лотереялары уйнату да бәйрәмгә ямь өстәде. Биредә төрле мебельләр, тузан суырткыч, чит илдә эшләнгән өс һәм аяк киемнәре, шулай ук башка дефицит саналган товарлар уйнатылды.

Хезмәтчәннәр бәйрәмне унйортлыкларда хәзерләнгән бәйрәм өстәле тирәсендә уздырдылар.

Шунысы куанычлы, кешеләр әле эшли дә, күңелле итеп ял да итә беләләр икән. Безнең юбиляр Федор Александрович Гущенны гына алыйк. Әнә ул 70 яшенә җитсә дә колхоз производствосында эшләүдән баш тартмый. Бүген аны туган көне белән котладылар.

Н. СИДОРОВА.

ЭШЛӘР БАР ӘЛЕ

Норлат элеваторында бүгенге көндә ашлык кабул итү һәм әзерләү эшләре туктатылды инде. Дөрес, килешү нигезендә бирегә диңгез аръягыннан бодай, кукуруз кайтарылды. Эшчеләр хәзерге вакытта шул вагоннарны бушату белән мәшгуль булдылар. Моңардан тыш Камада су күтәрелү сәбәпле, су юлы белән Чистай шәһәренә кирәк-яракларны китерү мөмкинлегечикләнгәнгә күрә, тимер юл белән безгә он китереп бушаттылар. Инде аларны яңадан төяп Чистай шәһәренә озатасы калды.

Коллектив агымдагы елның 9 айлык планнарын уңышлы үтәде. Ул планнан тыш 9 мең сумлык эш башкарды.

Ашлык кабул итү челтәрендә хәзер эш күләмекимү сәбәпле 63 кешене кыскартырга туры килде. Хезмәт җитештерүчәнлеге 135,7 процентка күтәрелде. Вагоннарны нормадан тыш туктап торуы 1 сәгать 8 минут тәшкил итә. Колхоз һәм совхозлар шул ук вакытта килешүдә каралган ашлыкны реализацияләү кагыйдәләрен үтәмәделәр. Нигездә III кварталда 294,2 мең сумлык югалтулар булды.

Ә катнаш азык җитештерү планы исә 111,5 процентка үтәлде һәм товар продукциясе 4438,6 мең сумга реализацияләнде. Әлбәттә, мондый уңышларга уртак тырышлык нәтиҗәсендә ирешелде. Тырыш эшчәннәр дә җитәрлек. Шундыйлардан, слесарь Владимир Кузьмин, Елена Абрамова һәм башкаларны атап үтәргә була. Алар үз эшләрен тырышып, намус белән башкаралар .

Г. РАЗЕТДИНОВА.

Иң кирәкле һөнәр иясе

Авылда ул кем диярсез... Һичшиксез, эретеп ябыштыручы Сәлих Мәүлетович Монасыйпов менә ике дистә елга якын инде колхозда танылган эретеп ябыштыручыга әйләнде. Авылда кем генә өендә пар белән җылыту җайланмасы үткәрергә уйласа да аңа мөрәҗәгать итә. Шулай итеп күпме йортка аның хезмәте керә. Көзге ремонт чорында да ул иң кирәкле кеше.

Ф. ВӘГЫЙЗОВА.
«Кондырча» колхозы.

Ишеттегезме әле?..

Быелның 25 ноябреннән шикәр һәм икмәккә бәяләр күтәрелә. Бу турыда мәрләр вәкилләре катнашында үткәрелгән Мәскәү хөкүмәте пресс-конференциясендә министр Владимир Карнаухов хәбәр итте. Шикәрнең килограммы 12 сум, бәлки 24 сум булыр. Икмәк һәм шикәргә бәяләрнең артуын исәпкә алып аларга өстәмә дотация 60 сум күләмендә билгеләнәчәк.

х х

Безгә хәбәр иткәнчә, Мәскәү шәһәре мәры икмәккә бәяләрнең күтәрелүе күптән программалаштырылган адым, диде.

Бүгенгә икмәкнең өч төренә генә бәяләр күтәрелде, ә киләчәктә бөтен икмәк коммерция бәяләре буенча сатылачак. Ә кара һәм ак ипи карточка белән биреләчәк. Бүген «өстән» билгеләнгән бәяләр,—вакытлы гына, ул ихтыяҗга карап үзгәрәчәк. Әгәр 5 сумлык ипине сатып алучы булмаса, аның бәясе төшәчәк. Әлегә кадәр бәяләрне күтәрү базарны баетмады, аннан алынган акча производствоны киңәйтүгә генә китәчәк.

Безнен Календарь

19 ноябрьдә Михаил Васильевич Ломоносовның тууына 280 ел

Ломоносовның бөек галим, физик, химик һәм язучы икәнлеген һәр укучы беләдер, мөгаен. Аның Төньяк Холмогордан егерме яшендә җәяүләп Мәскәүгә укырга килүен дә беләбез. Укый һәм академик була. Шуны ассызыклап үтик, Россия фәннәр академиясендә беренче рус академигы ул була. Барлык энциклопедияләрдә Ломоносов турында руслар арасында беренче дөньякүләм әһәмияткә ия табигать фәннәре белгече, шагыйрь, рус теле әдәбиятына нигез салучы, тагын рәссам, тарихчы, ватан мәгърифәтен яклаучы, рус фәне һәм икътисадын үстерүче дә булуы турында язалар. Бу бөек кеше белән без генә түгел, безнең оныкларыбыз да горурланачак. Рус җире әнә нинди кешеләрне тудырган!

Рәсемнәрдә: М.В. Ломоносов;

1741 елдан 1765 елга кадәр Михаил Васильевич Ломоносов эшләгән Санкт - Петербургтагы элеккеге Кунсткамералар бинасы.

ИШЕТМӘСӘҢ ИШЕТ

Миллион дигәннән. АКШта чыга торган кайбер массакүләм информация чаралары Ленинның бальзамланган гәүдәсе аукционнан сатылачак дигән хәбәр таратты. Анда әйтелгәнчә, СССР Эчке эшләр министрлыгы «юлбашчының» баштагы бәясен 15 миллион доллар дип билгеләгән.

Үзенең улын, кардәшен, дустын солдатка озаткан һәркем аны бик еш искә ала. Солдат хезмәте, моны үз башымнан үткәннәрдән дә чыгып әйтәм, җиңелдән түгел, шуңа аның ничек үтүе белән кызыксыну бик табигый.

Безнең гаилә дә бертуганыбызның улы Сергей Гузановны шулай тирән кичерешләр белән озатып калды. Сергейның әтисе автомобиль катастрофасына эләгеп үлде, шуңа күрә аны кызгана идек. Дөресен әйткәндә, ул аны сизми үсте, үзенә ташламаны теләмәде. Мәктәптә укыды, яшьтәшләре арасында тиң тотты, башкаларны җәберләмәде, үзен кыерсытырга да бирмәде.

Ул һава десанты гаскәрләрендә хезмәт итү турында хыялланды. Теләге чынга ашты. Моңа аның хәрби хезмәткә чакырылганчы 3 тапкыр парашюттан сикерүе дә «булышты» булса кирәк.

Хезмәтен Литваның Ислава шәһәрендә өйрәнү подразделениесендә башлады. Анда десантчының сугышчан машинасын йөртүче механик һөнәрен үзләштерде. Хәзерлегенә уңышлы үткәч, аны Үзбәкстанның Ферганә шәһәренә хезмәтен дәвам итү өчен җибәрделәр.

Быел июль азагында, чираттагы ялымны алгач, 12 яшьлек улым Сергей белән аны күреп кайтырга булдым. Якын юл түгел, поезд белән өч тәүлектән генә Ферганәгә килеп җиттек.

Ферганә үзәнендәге җәйге эссәлекне, ягъни чүлнең ак кояшы ничек кыздырганны һәркем белә, мөгаен. Температура плюс 40—42 градус:күктә ник бер болыт эсәре булсын да, яфрак селкенерлек җил булсын.

Кардәшләребездә туктап ял итеп алгач, шәһәр үзәгенә урнашкан хәрби частькә киттек. Бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, Сергей хезмәт иткән подразделение таулы өйрәнү үзәненә өйрәнүләргә киткән булып чыкты. Анысы Кыргызстанның Ош өлкәсендәге Уг-Курган шәһәренә янына урнашкан икән. Автобуска утырып анда юл алдык. Өйрәнү үзәгеннан читтәрәк, диңгез өстә тигезлегеннән 600 метр биеклектә өч курган арасындагы иңкүлектә булып чыкты.

Ниһаять, Сергей белән очраштык. Беренче күзгә чалынганы—ул үсә төшкән, кояшта каралган, җилкәгә дә киңәйгән. Бер сүз белән әйткәндә, чын десантчы булып җитешкән.

Кочаклашып күрештек. Ул туган ягын сагынган, авыл турында сораулары һич бетеп тормады. Яңалыкларның, ул киткәч булган үзгәрешләрнең барын сөйләдек.

Подразделение командиры белән очраштык. Ул улым белән миңа өйрәнү үзәгендә булырга рөхсәт итте. Десантчыларның ни белән шөгыльләнүен үз күзебез белән күрдек.

Десантчыларның өйрәнүләре бара иде. Аркаларына 24 әр килограмм таш салынган рюкзаклар асып, алар кечкенә тау (сопка) түбәсен «штурмларга» тиешләр иде. Мин яшьтән җиңел атлетика, чаңгы спорты белән шөгыльләнеп үссәм дә, штурмлаучыларның арттагылары рәтендә калдым.

Кичке аш учак янында үтте. Карабодай боткасы, ак май, консервланган ит һәм, бусына мин дә гаҗәпләндем, берәр шоколад бирелде. Җилә-кимеш һәм яшелчә өеп куелган иде, теләгән кадәр аша.

Кичке аштан соң десантчыларны пионер лагерена чакырганнар иде. Анда десантчылар 15 минут дәвамында асфальт өстендә кул сугышы алымнарын күрсәттеләр. Куәтле прожекторлар яктысында яшел аландагы «көрәш» тә файдалы булды. Берәүләр йодрык, сапер көрәге белән һөҗүм итте, икенчеләре аларны кире какты. Менә дигән тамаша булды бу. Азактан җыр һәм бию кичәсе булды.

Хәрби автомобильләрдә өйрәнү үзәгенә төнлә соң гына кайттык. Кайтып керүгә «отбой» булды. Тауда төнлә салкын, йокы капчыкларында яттык. Бик арыган булсам да тиз йоклап китә алмадым, таудан Ферганә үзәгенә бетон улаклар буенча челтерәп аккан су тавышы колакта гел чыңлады. Шулай да арганлык үзенекен итте.

Иртән безне таң белән күтәрделәр. Физзарядка 45 минут дәвам итте. Без дә арыктагы су белән юындык.

Рота командиры Сергейның чын сугышчы булуы турында сөйләде, аны яхшы тәрбияләгән өчен рәхмәт белдерде. «Сергейлар барысы да үрнәк хезмәт итәләр бездә»,—диде ул елмаеп. Хикмәт шунда ки, күптән түгел генә бу частьтә Иске Чаллы егете Сергей Никифоров та хезмәт иткән. Ул да, адашы кебек, солдат юлын намус белән узган. Сергейларның икесе дә «Минадан тазартканөчен» билгесенә лаек булганнар, һава десанты гаскәрләре командующиеның рәхмәтен алганнар.

Часть командиры Гузановка 2 көн ял бирде. Хәрби автомобиль безне Ферганәгә кадәр илтеп куйды. Без бергә рәсемгә төштек, шәһәрне карап йөрдек.

Туганыбыз янында булу солдат хезмәтенең катлаулылыгын, җаваплылыгын безгә янә искәртте.

И. ОСИПОВ,
милиция капитаны.

Якташларыбыз хәрби хезмәттә

ТУГАНЫБЫЗ ЯНЫНДА

Кимчелекләр читтә калмады

«Москва» колхозы профсоюз оешмасы җыелышында отчет доклады белән профком рәисе А. В. Паймурзин чыкты. Ул җирле комитет эшендәге уңай якларны һәм кимчелекләрне дә чагылдырды.

Фикер алышуда комплексны бригада бригадиры Н.П.Фомин, пилорамачы И. С. Фомин, колхоз рәисе А. Г. Гаврилов, хуҗалык агрономы К.Д. Ерепов һәм башкалар чыгыш ясадылар. Алар хезмәт дисциплинасын нык тоту, техника куркынычсызлыгы, торак йортлар төзү, пенсионерларны транспорт белән тәэмин итү мәсьәләләрен күтәрделәр. Халыкка медицина һәм сәүдә хезмәте күрсәтүнең торышына аерым игътибар бирелде.

Авыл мәдәнияте йортының эшмәкәрлеге дә борчу тудыра. Хуҗалык исәбенә тәзелгән бу объект бүгенге көндә хуҗасыз хәлдә. Ул, гадәттә, Совет карамагындагы объект булырга тиеш, әмма Илюткинонык ул үз балансына алмаган әле. Җыелышта да аны хәл итү булмады, мәсьәлә ачык калды. Кайчанга кадәр—билгесез.

Г. ХӘЛИУЛЛИНА.

ТАНЫШ БУЛЫГЫЗ:

«Заря» колхозының яшь шоферы Виктор Валерьянович Ермошкин.

Виктор урта мәктәптән соң Лениногорскида автомәктәпне тәмамлады, инде колхозда әйбәт кенә эшли. Җәйге чорда Виктор кырдан ындыр табагына ашлык ташыды, аның исәбендә 469 тонна күчерелгән бөртек исәпләнә. Хәзер Виктор үзенең ЗИЛ-554 автомашинасында җәмәгать малларына чөгендер түбе ташый. Тырыш, намуслы егетне хуҗалык җитәкчеләре гел мактап кына телгә ала. Мактамаслык та түгел, Виктор һәр эшне җиренә җиткереп башкарырга өйрәнгән һәм кайда эшләсә дә сынатмый. Әнә шундый уңганнар белән мактанырга да була.

Традицияләрне яңартырга

Башкарма комитетның чираттагы утырышына мәдәният учреждениеләре эше мәсьәләсе куелганын белгәч, әлеге тармак работниклары да, сәерсенү күрсәттеләр: аның нәрсәсен карыйсың, башкарылганы күз алдында, янәсе. Мәсьәләгә якын килеп карагач, ул тулырак ачыкланды.

Утырышта отчет тоткан Яңа Әмзә авыл культура йорты директоры Фәрит Гыйльметдинов көндәлек эш белән берәттән төрле бәйрәмнәргә спектакльләр, концертлар хәзерләү турында сөйләде. Иске Әмзә культура йортында да (директоры Әнвәр Шәйдуллин) шуңа тартым чаралар үткәрелә.

Тикшерү барышында эшләнгәннән эшләнмәгәне күбрәк әле дигән фикер чагылды. Һәм чыны да шулай. Элек мәдәният учакларында кызыклы яшьләр кичәләре, диспутлар оештырыла килгән. Сугыш ветераннары белән очрашулар үткәрүгә дә әһәмият кимегән. Яңа өйләнешкән яшьләрнең үрнәк гаиләләр белән түгәрәк өстәл артында сөйләшүләре дә ни өчендер хәзер узмый. Матур традицияләрне яңарту кирәклеге күрсәтеп үтелде утырышта.

Сөйләшү барышында Чурабатыр, Кызыл Юл клублары эшен җанландыру кирәклеге билгеләп үтелде. Анда яшьләр юк дәрәҗәсендә, шул сәбәпле халыкны җәлеп итәрлек чаралар да үткәреп булмый, клублар кино күрсәтү белән чикләнәләр.

Утырышта халыктан арткан терлекчелек продуктларын сатып алу заданиеләрен үтәүнең торышы анализланды. Бу мәсьәләә буенча халык депутатларының Яңа Әмзә авыл Советы рәисе Рәхимҗан Вәлиуллин чыгыш ясады, планнарны үтәүне тәэмин итүгә игътибар юнәлдерде.

Башкарма комитет социаль яклауга мохтаҗ картларга, карчыкларга ярдәм күрсәтү мәсьәләсе буенча да практик чаралар билгеләде.

Г. НӘБИУЛЛИНА.

Әмзә авыл Советында

Уңган сөт җыючы

Рифкат Сәхипгәрәевна авыл халкы тынгысыз кеше саный. Ә халык һәркемгә бәяне гадел куя, ул чынлап та шундый. Хезмәте гади генә аның, сөт җыючы. Һәм шуны намуслы башкара. Карбуран булса да, яңгыр яуса да туктатмый үз эшен. Ул хәзерләүче булып эшләгән Яңа Әмзәдә 80 баш сыер исәпләнә. Ел башыннан бирле бер сыерга уртача 804 килограмм сөт сатып алуны тәэмин итте инде.

Авыл халкының бу эштә актив катнашуын да әйтеп узарга кирәк. Роза Локманова ноябрь башына 4019 килограмм сөт сатты. Рәсимә Гайнетдинова исә шул вакыт эчендә хәзерләүчегә 3305 килограмм сөт тапшырды. Хәлимә Мотаһирова, Сания Гайнетдинова, Гайния Сәхипгәрәева да үз гаиләләреннән арткан продукцияне ил табынына теләп озаталар. Аларның һәркайсы хәзерләүчегә 2 мең килограммнан артык сөт бирде. Гаиләләреннән мең килограмм һәм аннан да артык сөт сатучылар да байтак.

Уңган сөт җыючы Сәхипгәрәев индивидуаль сектордан сөт туплауны дәвам итә.

Р. ЗАҺРЕТДИНОВ.

Александр Николаевич —«Заветы Ильича» колхозының уңган ирләреннән берсе. Менә ун елдан артык инде ул җәен комбайнчы буларак кырлар иңли, елның калган вакытында трактор йөртә. Быел да ул урыҗыю чорында «Нива» комбайнында эшләде һәм уңыш нәтиҗәләре буенча колхозда өченче урынга чыкты.

А. Н. Корнеевны авылда эшчән, тырыш булганы өчен генә түгел, уңган, тату гаилә башлыгы буларак та ихтирам итәләр.

...Авылда ел әйләнәсенә эш кимеми, бер мәшәкатьне икенчесе алыштырып тора. Александр Николаевич та комбайнын тракторга алыштырды. Бүгенге көндә ул терлекләр өчен салам, ферма котельные өчен ягулык күмер ташый.

«Заветы Ильича»да терлекләрне кышлату чоры мәшәкатьләре Корнеев кебек ир-егетләрнең ныклы кулына тапшырылган.

Рәсемдә: А. Н. Корнеев —җәен урак басуында.

Н. Азизов фотосы.

ТӨГӘЛЛЕК ЯРАТУЧЫ

Вахтаны төяп Яңа Чишмә районына кузгалганда ук буран себерә, юлга кар сала башлаган иде инде. Җил көчәя барды, буран котыра ук башлады. Елховойны чыккач, автобус чираттагы көрткә килеп керде һәм туктады.

Вениамин, моторны сүндермичә генә, карны ишәйтә юлдашы Володя янына атлады. Аны күреп Логинов та кабинасыннан төште.

—Бүтән барып булмый, —диде Вениамин.

—Хәзер кире дә борылып булмый инде,— диде Логинов аны җөпләп.—Көтеп карасак кына.

Ә көтәргә шактый туры килде. Ул арада, эч пошканнан, тәмәке тартып вакыт уздырды Вениамин Анатольевич. Нинәять, арттан килүче машина фараларының уты күренде.

Кар ерып килүче куәтле «Урал» булып чыкты ул. Буровой вахта эшчеләрен аңа күчереп утырттылар. Ул киткәч, радиатордан суларын агызып үзләре кар ераера утлары күренеп торган Елховойга төн кунарга киттеләр.

Төне буе котырган буран тац алдыннан басылды. Алар автобусларын җылытып кабызганчы нефтьчеләргә хезмәт күрсәтүче куәтле машиналар узып өлгерде, шулар эзеннән кайтырга чыктылар.

Еш булмаса да, мондый хәлләр очраштыра тора, шоферлар сукмагында. Вениамин Анатольевич тормышында да, саный китсәң, андый очраклар байтак җыела. Элек, асфальт юл салынганчы, бигрәк тә.

—Хәзер автопредприятиедә шартлар шактый үзгәрде инде,—дип искә ала Зайцев.—Мин бирегә эшкә килгәндәге белән чагыштырып булмый.

Ә бирегә 1975 елда килә ул. Йөк машинасына шофер булып. Билгеле инде, яңа килүчегә иске йөк автомобилен тапшыралар.

Хәер, анысы Зайцев өчен бу яңалык түгел инде, аңа кадәр райпо автогаражында, үзе әйтмешли андый машиналар белән берничә ел чиләнергә туры килде инде аңа. Кече яшьтән техникага хирыс Вениамин машина «серләрен» аңа кадәр ук тулы үзләштереп өлгергән иде, җиң сызганып алынды, аны тиз сафка бастырды.

Шофер өчен тормышның күп өлеше юлдан тора. Һәр иртә машинаңны кабызасың һәм рейска чыгып китәсең. Көн дә яңа маршрут, юлда яңа кешеләр очратасың. Күңеле тарткан һөнәр булгач, шагыйрь әйтмешли, юл йөрүдән һич тә бизми Зайцев. Һөнәре күпләр өчен бик гадәти тоелса да, үтә җаваплы хезмәт үзе. Юлда кар, бураны гына түгел, башкалары да килеп чыга бит: хәрәкәт кагыйдәләрен санга сукмаучы исеркеләр дә очрый. Үзең хәмер белән мавыкмасаң да, шундыйлардан сак булырга кирәк. Бозлавык вакытта һәр хәрәкәтеңне төгәл үлчәп йөрү, аек исәп зарури. Зайцев, тфү-тфү, юлда һәрчак сизгер, уяу. Шуңа унбиш елдан артык юлда бер авариясез йөри дә.

Шуны исәпләп, берничә ел эшләгәч, аны автобуска күчерәләр дә. Рейс саен үзенә дистәләрчә кешеләр язмышы ышанып тапшырылганны аңлап чыга ул юлга.

Үткән ел аңа яңа автобус тапшырдылар. Аның белән эшләве күпкә җиңел. Су урынына радиаторга тосол салынган, моторны да лампа белән двигатель астына кереп җылытасы юк. Шуңа чагыштырмача күп уңай аңа.

Чагыштырмача, чөнки рейска хәзерләнүнең башка мәшәкатьләре дә бар әле аның. Ул һәркөн иртән сәгать 4тән аяк өстендә. Ноябрьдә ул нефтьчеләрне икенче промыселга—Күтәмәгә йөртә. Вахта белән иртәнге 6 дан юлга чыга. Ә аңа кадәр машинаны карап-көйләп, ягулык та саласы бит әле. Билгеләнгән вакытка соңармый килеп җитә Зайцев. Эштә төгәллеккә күнеккән ул. —Татарстанның атказанган автотранспорт работнигы.

Р. АЙЗАТУЛЛИН.

Техника кырда сынатмас

Авылда кызу эш өстә. Болай дигәч, күз алдына сары башакларын җиргә игән иген басулары, шул басулардагы борыннарны кытыклый торган ашлык тузаны эченнән килүче кыр кораблары күз алдына килә. Әмма бит авылда елның һәр мизгеленда кызу эш өстә. Әнә хуҗалыкның механикалаштырылган мастерскоенда урак өстеннән дә кызу эш бара. Хәзерге вакытта техника ремонтлау механизаторлар өчен беренчел бурыч. Ремонт өчен кирәк-ярак юнәтүе җиңел түгел. Ә инде машина һәм агрегатларга запас частьләр турында хыялланырга гына кала. Шуңа да кирәкле узел һәм детальләрне генә түгел, бәлки һәр шөрепне исәптә тоталар биредә.

Слесарь-көйләүчеләрнең хәрәкәтенә карап торуы да күңелле, аларның нык бармаклары ышанычлы тота һәр детальне, шөрепне.

20 еллык эш стажы булган электр белән эрәтеп ябыштыручы Һади Хөснелгата улы Галимов металлга куйган җөйләр ышанычлы, мәңгелек. Авыл тимерчесе Галимҗан Нуретдин улы Зәбировның хәрәкәтләре сабыр һәм төгәл. Аларның төгәллеге эштә зур тәҗрибәле булуында. Бу останың тимерче булып эшли башлавына 32 ел гомер узган икән. Ярдәмчесе Хәбибулла Кәлимулла улы Рәхмәтуллин да остазына тиң. Ул үз эшен яхшы белә, бар тырышлыгын куеп эшли. Ә тырышкан таба—ташка кадак кага, дип нәкъ шундыйларга әйтәләр дә инде.

Кайсы механизатор ремонт эшен тулысы белән слесарь җилкәсенә сала. Юк, һәр узелын, һәр шөребен үз кулларың белән барлап чыксаң гына үзеңә ышанып тапшырылган техниканың ышанычлы эшләвенә ирешәсең дип исәплиләр тракторчылар Хатыйп Хөсәен улы Гайнетдинов һәм Госман Хәбибулла улы Зәйдуллин.

Токарь булып 15 ел эшләүче һәм хәзерге вакытта гараж мөдире вазифасын башкаручы Хәлил Хөсәен улы Гайнетдинов алар белән килешә.

Муса Җәлил исемендәге колхозда яшь алмаш үсә. Механизатор Якуб Әхмәтсәгыйров шуларның берсе. Ул тракторга армиягә киткәнче утырган һәм аннан кайткач та техникадан аерылмаган. Якубның күптән түгел генә кызы—Миләүшә туган. Әлеге яшь атаны туган авылы белән нык тамырлар бәйли. Һәм бу тамырның ныклыгына, өзелмәслегенә өметләнергә генә кала.

Г. ХӘЛИУЛЛИНА.

Ничек яшисең, коллектив?

Үзгәрешләр уңайга илтә

«Татжилгражданстрой»ның Норлат ремонт-төзелеш участогы соңгы елда гына шактый үзгәрешләр кичерде, ә төгәлрәк итеп әйткән дә, материаль базасын ныгытты, яңа эш чыганаклары барлыкка китерде, эшчеләр өчен байтак кына уңайлыклар тудырды.

Хәтердә әле, үткән ел гына стадион кырында спорткомплекс төзүне башлагач: «Измә юк, төзелеш оешмалары китермиләр», дип моң-зарлары белән бүлешкән иделәр участок җитәкчеләре. Бу хәл һәр эшкә алынган саен зур борчу тудыра килде. Шуңа да үзләрендә битум цехы ачу аларның күптәнге хыялына әйләнде. Һәм, нинәять, биредә битум җитештерелә башлады. Цех өчен яңа җайланма 100 мең сумга төште. Ул сәгатенә 25 куб метр битум җитештерә. Шунда ук окисьлаштыру җайланмасы да урнаштырыла. Цехта мастер —Харис Исмәгыйлевич Сираҗев. Ул Рәшит Җиһаншин һәм Камил Гобәйдуллин белән берлектә җайланмаларның төзеклеген саклап, даими эш ритмын тәэмин итеп тора. Хәзер участок битумны төрле бартер операцияләре өчен дә файдалана ала.

Быелгы тугыз айлык төзелеш планының узган елгыга караганда 20 процентка арттырып үтәлүе дә битум цехы ачылуның уңай якка баруы хакында сөйли, әлбәттә. Үткән елгыга караганда 36 мең тоннага күбрәк асфальт түшәделәр. Зирекле авылын олы юл белән тоташтыру, «Рассвет» совхозы, «Ленинский путь» колхозыннан юллар салу, шулай ук тимер юлчылар поселогында юллар үткәрү һәм башкалар алар кулыннан узды. Иван Иштуллин, Владимир Сычев, Ибраһим Ганиев, Минсәлих Гобәйдуллин берөзлексез асфальтны цехтан тиешле җиргә ташып торалар. Ә асфальт түшәүчеләрдән Васыйл Мирзаевич Сибгатуллин бригадасы мактауга лаек. Бригадада Рафик Әбҗәббаров, Николай Кузьмин, Аркадий Федоров, Петр Савгачев зур тырышлык күрсәтәләр.

Участок цех ачу белән генә чикләнмәде: кирпечне дә үзе җитештерү юларын кайгырту белән мәшгуль булды. Шулай итеп, Чуваш Мәнҗесе авылында кирпеч заводы эшкә кереште. Хәзергә биредә 500 меңләп кирпеч сугылды.

Йортлар салу да юллар түшәү кебек үк ремонт-төзелеш участогының иң мөһим функцияләренә керә. Ул ике, дүрт, тугыз фатирлы йортлар сала. Яшь мастер Альберт Сатдаров, бригадир Ильяс Хәсәнҗанов, ташчылар Шамил Алтынбаев, Нәҗип Хәмидуллин, Юрий Павлов, Фәүзия Ильмухина бригадасындагы мастер Вәзәрия Шәфыйковна Гыйззәтуллина, штукатур-буяучылар Минегаян Тажиева, Люция Хәммәтова, Миннегөл Әхмәтова төзүчеләр арасында иң мактаулылардан саналалар. Биредә фатирларда ремонт белән шөгыльләнүче бригадалар хакында да җылы фикерләр әйтәләр. Хәтта кайбер йортлардан рәхмәт хатлары да алынган. Мәсәлән, балта остасы Федор Трофимович Макушенкодан бик канәгать булып калалар. Ул ике дистә еллар биредә хезмәт итә. Тырыш, сыйфатлы хезмәте аркасында аңа «ТССРның атказанган төзүчесе» исеме бирелде.

Участокта агач осталары Петр Михайлович Спасов, Ильяс Хәмәтвәлиевич Мәгыйзов, Владимир Петрович Рязанов үзләренең хезмәте, башкарган эшләре белән күп урында таныдылар. Шәһәр гастрономында булган кеше зәвык белән бизәлгән соклар, эчемлекләр сату почмагын күрми калмагандыр. Бу нәкъ шул оста кулларның хезмәт җимеше. Шуңа охшаган бизәлешне кайбер оешмаларда һәм балалар ясле-бакчаларында да эш очратырга була.



Соңгы бер-ике айда гына да ремонт-төзелеш участогында тагын бер яңалык күзгә ташлана башлады. Ул идарә каршында ачылган «Салон-магазин». Биредә участокның алтын куллы кешеләре Сергей Грачев һәм Марат Галиев ярдәмендә участок үзе әйберләр сата башлады. Сәүдә витринасында аларның нәфис бизәкләре, рәсемнәр төшергән плиткалары урынны алган. Шулай ук биредә плинтуслар, рейкалар, машиналар өчен амортизация втулкалары сатыла, Һичшиксез, цех ачылу, кирпеч заводы эшли башлаудан килгән кебек, «Салон-магазин»нан да участокка шактый табыш килә башлады.

Ф. ГАЛИМОВ.

ТЕЛЕВИДЕНИЕ

СИШӘМБЕ
19 НОЯБРЬ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

18.40 Хәрәкәт иминлеге өчен.
19.00 Татарстан.
19.30 Телебиржа.
20.10 Әлли-бәлли-бәү.
20.20 Язучы фикере. М. Мәһдиев.
20.40 Тапшырулар программасы.

I ПРОГРАММА

6.30 Иртә.
9.00 Мультфильм.
9.15 Балалар сәгате.
10.15 «Байлар да елый икән». 2 серия.
10.55 Концерт.
11.30 Документаль фильм премьерасы: «Йөрәккә операция».
12.00 «ТЯХ».
12.10 Еллар аша көлү.
13.25 «Лад» ансамбле чыгышы.
13.40 Куен дәфтәре.
13.45 Биржа яңалыклары.
14.00 Телемикст.
14.45 Сәүдә рәте.
15.00 «ТЯХ».
15.15 Болар булды инде, булды...
15.35 «Җиңелү». 2 серия—«Ярымхакыйкать».
17.00 Балаларның музыка клубы.
17.45 Чемпионнар белән бергә.
18.00 «Шалом». «Алия» яһүд музыкасы ансамбле белән очрашу.
18.30 «ТЯХ».
18.45 Мультфильм.
19.00 Һәвәсләр дөньясы.
19.15 Документаль фильм премьерасы: «Өмет августы».
20.20 Нәфис фильм премьерасы: «Байлар да елый икән». 2 серия.
21.00 Информацион программа.
21.40 Сәхнәнең арткы ягында.
22.25 Акробатик рок-н-ролл. СССР чемпионаты.
23.25 «ТЯХ».
23.40 Музыкаль программа: «Төшләремә нигә керәсең».
00.20 Епископ В. Родзянко белән әңгәмәләр. 21 нче тапшыру.
00.45 Киноконцерт: «Барлык йолдызлар да».
01.35 Нәфис фильм: «Йолдыз санаучы». 1 серия.

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Мультфильм.
8.25 Француз теле. 1 укулы.
8.55 Француз теле. 2 укулы.
9.25 Компьютер белән диалог.
10.00 Бокс буенча дөнья чемпионаты. Австралия-дән трансляция.
13.00 О. Лундстрем җитәкчелегендә джаз-оркестр һәм Д. Браун (АКШ) концерты.
14.15 Ритмлы гимнастика.
14.45 И. Гайдн. Солистлар, хор һәм симфоник оркестр өчен Ре Минор (Нельсон-месса) массасы.
17.00 «Орнамент» ансамбле чыгышы.
17.15 Сәяхәтчеләр клубы.
18.15 Эшкуарлык һәм традицияләр.
21.45 Океан артыннан ярдәм.
22.00 Герард Васильев. Урыс романсы.
22.25 Шуннан шунда кадәр.
22.55 Реклама.
23.00 Хәбәрләр.
23.20 Бокс буенча дөнья чемпионаты.

ЧӘРШӘМБЕ
20 НОЯБРЬ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

18.10 Хокук сагында.
18.40 В. Ефимов җырлый.
19.00 Татарстан.
19.30 «Турыдан-туры элемтә». «Рухи мирасны халыкка».
20.30 Әлли-бәлли-бәү.
20.45 «Театр сәхифәләре», Ш. Сарымсаков сөйли.
21.30 Тапшырулар программасы.

I ПРОГРАММА

6.30 Иртә.
9.00 Мультфильм.
9.30 Балаларның музыка клубы.
10.15 «Байлар да елый икән». 3 серия.
11.00 Цирк программасы: «Сәхифәләрне актарганда».
12.10 Рәссам Жигальцевның агач кешеләре.
12.30 Сәхнәнең арткы ягында.
13.15 Халыкара Чернобыль проекты.
13.45 Биржа очучысы.
13.55 Куен дәфтәре.
14.00 Партнер.
14.30 Икътисади агентлык.
12.00 «ТЯХ».
15.15 Бүген һәм ул чакта...
15.45 «Җиңелү. 3 серия.—«Гаделлек һәм ярымхакыйкать».
17.10 Мультфильм.
18.30 «ТЯХ».
18.45 Планета.
19.15 Фулл-контакт каратэ һәм кикбоксинг. Халыкара ярыш.
20.00 Һәвәсләр дөньясы.
20.15 Нәфис фильм премьерасы: «Байлар да елый икән». 3 серия.
21.00 Информацион программа.
21.40 Язучы Ф. Искәндәр белән Останкиноның концерт студиясендә очрашу.
22.55 Кыска метражлы фильм премьерасы: «Бирелмәгән темага спектакль».
23.35 Телевизион яңалыклар хезмәте.
23.50 Кинопанорама.
01.50 Документаль фильм премьерасы: «Иоганн Себастьян Бах. Тормышының сәхифәләре». 2 нче фильм.
02.05 Нәфис фильм: «Йолдыз санаучы». 2 серия.

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.25 Немец теле. 1 укулы.
8.55 Немец теле. 2 укулы.
9.25 Менеджерлар мәктәбе.
10.00 Бокс буенча дөнья чемпионаты.
13.00 А. С. Пушкин. «Пики дамасы».
14.25 Документаль фильм: «Упкын читеннән репортаж».
15.15 Дагстанның «Лезгинка» бию ансамбле чыгышы.
17.00 Н. Раутис башкаруында Г. Свиридов романслары.
17.35 Менеджерлар мәктәбе.
18.05 «Хәзер». Дини тормыш яңалыклары.
18.40 Криминал хәбәрләре.
22.25 РСФСР Югары Советы сессиясендә.
22.55 Реклама.
23.00 Хәбәрләр.
23.20 Бокс буенча дөнья чемпионаты.

ПӘНҖЕШӘМБЕ
21 НОЯБРЬ
КАЗАН КҮРСӘТӘ

18.10 Мультфильмнар.
18.30 «Сез дип сөйләшә башлыйм!» Ничек яшисең. Базар?
18.50 Реклама.
19.00 Татарстан.
19.30 Депутат каналы.
20.10 Әлли-бәлли-бәү.
20.20 Шигъриять. «Кешеләргә ышанасым килә». И. Иксанова.
20.30 Тапшырулар программасы.

I ПРОГРАММА

6.30 Иртә.
9.05 Мультфильм.
9.25 Балалар сәгате.
10.25 «Байлар да елый икән». 4 серия.
11.10 Киноконцерт: «Барлык йолдызлар да».
12.00 «ТЯХ».
12.10 МВД хәбәрләре буенча.
12.25 Язучы Ф. Искәндәр белән Останкиноның концерт студиясендә очрашу.
13.40 «Икътисади агентлык.
14.10 Куен дәфтәре.
14.15 Телемикст.
15.00 «ТЯХ».
15.15 Мультфильм: «Барлык шайтаннарга ачу итеп».
15.35 «Җиңелү». 4 серия.—«Хакыйкатькә орыну».
17.00 Документаль фильм премьерасы: «Кайчан да булса без бәхетле булырбыз».
17.30 Һәвәсләр дөньясы.
17.45 Экология. Җәмгыять. Кеше.
18.30 «ТЯХ».
18.45 МВД хәбәрләре буенча.
19.00 ...16 яшькә кадәр һәм өлкәнрәк.
19,45 Дипломатик булмаган әңгәмәләр.
20.15 Нәфис фильм премьерасы: «Байлар да елый икән». 4 серия.
21.00 Информацион программа.
21.40 Музыкага чакыру. Тәнәфестә (22.35)—Телевизион яңалыклар хезмәте.
23.40 «Плюс» театры ангажементы.
01.15 Документаль фильм: «Үз чираты җитәр».
02.15 Нәфис фильм: «Йолдыз санаучы». 3 серия.

II ПРОГРАММА

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 Испан теле. 1 укулы.
8.45 Испан теле. 2 укулы.
9.15 Рус теле.
9.45 Италияләр Россиядә. Ике айдан соң.
10.13 А. П. Чехов. «Акчарлак».
11.00 Ак карга булдым инде.
12.00 Мультфильм.
12.15 «К-2» күрсәтә: «Абзац».
13.00 Кубан туе.
13.35 «Көнчыгыш Сәбер» киножурналы.
13.41 Ритмлы гимнастика.
14.15 Фильм-концерт: «М. И. Глинка. Романслар».
17.00 Күпне белүчеләр өчен күнегү.
17.30 Рус теле.
20.35 Бишенче тәгәрмәч.
22.25 РСФСР Югары Советы сессиясендә.
22.55 Реклама.
22.00 Хәбәрләр.
23.20 Бонн җәе.

Янәшәбездә әйбәт кешеләр

—Су җылынганчы, минем балалайканы көйли тор әле, Федя абый, зинһар. Үземнең бик барып чыкмый.

—Шуның кайгысымны миндә, Валя—дим, авыртудан түзә алмыйча сыкранып.

—Зарарсыз,—дип елмая ул. —Күрерсез... хәзер биерлек ясыйм мин сезне.

...Минем аяк дәвалау процедурасы озак бармады. Тәбәнәк урындыкка утыртып, ул минем теземне бармаклары белән капшый башлады.

—Менә кайда тайган урыны!

Шуннан ул аякның шул җирен сабынлап сыларга тотынды. «Аһ» дияргә өлгермәдем, шыртлаган тавыш ишеттем.

—Курыкма, булды, хәзер аягыңны селкетсәң дә була.

Шуннан ул кулларын юып, чынлап та балалайкасын алып «Барыня»ны уйный да башлады. Мин дә яшьлектәге кебек чүгәләп биеп җибәрергә әзер идем бу минутта.

—Рәхмәт, Валя...Валентина Дмитриевна!—дим чын күңелдән.

...Хәзер бу хәлне аңлатыбрак сөйләүгә күчәм.

Өч көн элек автобустан төшкәндә ялгыш аягымны тайдырдым. Биредә ялгыш дип әйтү дөрес тә булмас, чөнки безнең автобус тукталышларындагы чокыр-чакыр, пычракта кеше генә түгел, кем әйтмешли, шайтан да аягын сындырырлык.

—Берәр әбигә барыга,—дип кинәш иттеләр миңа. Ләкин кайда, кемгә? Шунда миңа Шентлыда, Норлатта яшәүче «белгечләрнең» адресларын әйттеләр. Минем исемемне Үзебезнең Егоркино авылында да шундый кешеләр барлыгы исемә төште. Ничектер кешеләрдән ишеткәнем бар иде. Менә хәзер аның янында утырам. Дәвалау процедурасыннан соң без сөйләшеп киттек.

Валентина Дмитриевна Яковлеваның яше инде алтмышны узган. Яшьтән колхозда икмәк, чөгендер үстерүдә катнашкан фермада хезмәт куйган. Хәзер пенсия яшендә булса да ул механизаторларга төшке аш пешерә.

—Ә кем сезне дәвалаучы серләренә өйрәтте?—дип кызыксынам мин.

—Бу минем әнидән калды. Ул үзе йөзгә кадәр яшәде. Ул картайгач, мин аңа булыша идем. Аннары үзем мөстәкыйль рәвештә дәвалый башладым. Шуннан китте инде.

—Минем бернинди яшерен серем юк. Белгәнемне бик теләп өйрәтер идем. Тик яшьләрдән хәзергә теләүчеләр юк.

—Ә син әбиең кебек булырга телисеңме?—дип сорыйм янәшәмдәге шук кызчыктан.

—Юк!

Ә бик кызганыч...

Ф. САВГАЧЕВ.

Котлыйбыз!

Октябрь районының Түбән Норлат авылында гомер итүче кадерле әниебез Минбанат Мингәрәй кызы Хисмәтуллинага 50 яшь тулды. Сөекле әниебез! Сине юбилеең белән кайнар котлыйбыз! Сиңа озын гомер, саулык-сәламәтлек, картлык көненә тыныч бәхетле тормыш, куаныч-шатлыклар телибез. Һәммәбезнең күңелен җылытып, терәгебез һәм кайгыртучыбыз булып озак яшә. Алдагы көннәрең аяз, кояшлы булсын. Әти белән бергә шатлык-куанычлар күреп, кайгы-хәсрәтсез гомер итегез.

ИҢ ИЗГЕ ТЕЛӘКЛӘР БЕЛӘН ТОРМЫШ ИПТӘШЕ ШӘРИФУЛЛА, УЛЛАРЫ, КЫЗЛАРЫ, КИЛЕНЕ, КИЯҮЛӘРЕ ҺӘМ ОНЫКЛАРЫ.

«НОРЛАТ СӘҮДӘ ЙОРТЫ» ФИРМАСЫ

барлык кызыксынган предприятиеләргә, оешмаларга һәм аерым кешеләргә үзара сәүдә мөнәсәбәтләре урнаштырырга тәкъдим итә.
Без сезнең тарафтан тәкъдим ителгән яки соралган продукцияне тиз арада табуны яки отышлы рәвештә сатып алуны гарантиялибез.

Безнең адрес: Совет урамы, 117
Телефоннар: 2-14-69, 2-15-96.

КӨЛЕШЕП АЛЫЙК

—Улым, ник әтиең әйберенә тидең, хәзер пешерә бит үзеңне.

—Кайгырма, әни, газ да бетте, ут та сүнде, мич тә ягылмаган.

х х х

—Бүген аквариумга яңа су салдыңмы?

—Бигрәк тә ялкау балыклар булып чыктылар, алар кичәге суны да эчеп бетермәгәннәр...

МӨХӘРРИР Ә. У. АБДУЛЛИН.

Учредитель: халык депутатларының Октябрь район Советы.
Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары —2—15—63, социаль-экономика бүлеге—2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор Зөлфия ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
ТССР информация һәм матбугат Министрлыгының Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак,
Заказ 138. Тираж 3413.